КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1235

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 ноябрь, 1105 нче карары белән расланган Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 ноябрь, 1105 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 май, 490 нчы; 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек

субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

6 пунктның өченче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин